| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ЭБАЛАКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯБАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 30 нчы сентябере Ябалак авылы № 113

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Бәрлебаш авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Уставының 22статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2019 елның 22 октябрендә 12 сәгать 00 минутка Бәрлебаш авылы,Вахитов урамы,2А йорт адресы буенча урнашкан Күпфункцияле үзәк бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегендә Бәрлебаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә:

2. 2019 елның 23 октябрендә 09 сәгать 00 минутка ҖЧҖ «Дубрава» агрофирмасының Бәрлебаш филиалы сөтчелек фермасы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Бәрлебаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Ябалак авыл җирлеге Бәрлебаш авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- җирлектәге торак пунктлардагы чүплекләрне чистарту;
- материаллар сатып алып, күпер ремонтлау;

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ябалак авыл җирлеге башлыгы Гыйзәтуллина М. Ф.